ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.07.2019 п.г.т.Алексеевское № 297

**“Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларны туктату һәм билгеләү тәртибе турында” Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2012 ел, 17 гыйнвар, 9 нчы Карарына үзгәрешләр кертү турында**

2019 елның 26 февралендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарына туры китереп “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында” 2011 ел, 12 август, 660 нчы Карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 391 нче карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү турында”

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибенә кертергә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында “2012 елның 17 гыйнварындагы 9 номерлы карары белән расланган” Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында” гы карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләр кертелде:

- 1нче пунктны “Россия Федерациясе Җир кодексының V. 7 бүлегендә каралган очраклардан тыш сүзләрен өстәргә”;
- 3 нче пунктны түбәндәге редакциядә дәвам итәргә

«3. Ачык сервитут кемнәр өчен билгеләнә:

1) җир кишәрлеге аша узу яки йөрү, шул исәптән максатта гомуми файдаланудагы су объекты янына һәм аның яр буе полосасына гражданнарның ирекле үтүен тәэмин итү;

2) җир кишәрлегендә межалау билгеләре, дәүләт геодезия челтәрләре пунктларының геодезик билгеләрен урнаштыру, гравиметрик пунктлар, нивелир пунктлары һәм аларга керү юллары;

3) җир участогында дренаж эшләре үткәрү;

4) су объектларыннан су ресурсларын алу;

5) җир кишәрлеге аша авыл хуҗалыгы терлекләрен куу;

6) җир кишәрлекләрендә билгеләнгән тәртиптә авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү, печән чабу, болар барысы да җирле гореф-гадәт һәм андагы алшартларга туры китереп башкарыла;

7) аучылык һәм балыкчылык максатларында җир кишәрлеген, аквакультураны (балыкчылыкны) куллану.

- 16 пунктның беренче абзацында «җир кишәрлегенең кадастр паспортына» сүзләрен "күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына сүзләренә алмаштырырга";

- 17 пунктның өченче абзацында «күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрында» сүзләрен «күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутларның гамәлдә булуын билгеләү һәм туктату тәртибен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М. Р. Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**